ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

«10» август 2026 ел Яр Чаллы №2714

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатында 2026 елның III кварталына Тукай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метры бәясе нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2026 елның 9 февралендәге 39 номерлы хаты нигезендә һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 19 июнендәге 388/пр номерлы боерыгын исәпкә алып,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча чаралар үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 2026 елның өченче кварталына Тукай муниципаль районы территориясендә гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясен 85000 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов